## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2015 елның 1 апреле 10№

Иске Салман авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлки муниципаль районының «Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советына дәүләт милке чикләнмәгән һәм Иске Салман авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен кабул итәргә тәкъдим итәргә.

2. Әлки муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта итеп бирелгән рәвештә тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 декабрендәге «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге бюджеты турында»33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләү һәм карауны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Иске Салман авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Салман авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Җәләлетдинов